КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

611-П № 04.12.2024

Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча эзләп табылган «Стахеевлар йорты, XIX гасыр ахыры» мәдәни мирас объектын, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертү, мәдәни мирас объектының сак предметын билгеләү, чикләрен раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2024 елның 17 нче ноябренә караган уңай бәяләмәсенә нигезләнеп боерам:

1. Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча эзләп табылган «Стахеевлар йорты, XIX гасыр ахыры» мәдәни мирас объектын, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры (объект төре - һәйкәл) төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертергә

2. Әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының сак предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
4 нче декабрендәге 611-П
номерлы боерыгына
караган 1 нче кушымта

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты

**территориясе чикләре**

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)




Масштабы 1:500

Условные обозначения:

| | |
|---|---|
| 1 | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе |
| 16:28:180187:98 | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләре |
| | - җир кишәрлекләре арасындагы чик |

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең текст тасвиламасы

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәге урыннардан уза:

| Чикнең узу урыны | | Чикнең узу урынының тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктадан | |
| 1 | 2 | 1 нче ноктадан 21,71 метр ераклыкка, көньяк-көнчыгыш юнәлештә һәйкәлнең төньяк-көнчыгыш фасадына параллель рәвештә 2 нче ноктага кадәр; |
| 2 | 3 | 2 нче ноктадан 23,52 метр ераклыкка, көньяк-көнбатыш юнәлештә һәйкәлнең көньяк-көнчыгыш фасадына параллель рәвештә 3 нче ноктага кадәр; |
| 3 | 4 | 3 нче ноктадан 21,71 метр ераклыкка, төньяк-көнбатыш юнәлештә һәйкәлнең көньяк-көнбатыш фасадына параллель рәвештә 4 нче ноктага кадәр; |
| 4 | 1 | 4 нче ноктадан 23.52 метр ераклыкка, төньяк-көнчыгыш юнәлештә һәйкәлнең төньяк-көнчыгыш фасадына параллель рәвештә 1 нче ноктага кадәр. |

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы нокталар таблицасы

| № | Җирле координаталар системасында характерлы нокталарның координаталары (ҖКС-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 468100.11 | 2367662.67 |
| 2 | 468088.55 | 2367681.05 |
| 3 | 468068.64 | 2367668.53 |
| 4 | 468080.20 | 2367650.15 |
| 1 | 468100.11 | 2367662.67 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
4 нче декабрендәге 611-П
номерлы боерыгына
караган 2 нче кушымта

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
**сак предметы***

1. Урыны: Ленин урамының тарихи Кызыл линиясендә.
2. Әйләнә-тирәдәге табигый һәм мәдәни ландшафт структурасында композицион әһәмияте (роле).
3. Һәйкәлнең габаритлары, силуэты: тарихи кирпеч диварлар чикләрендә.
4. Һәйкәлнең күләм-киңлек композициясе: планында турыпочмаклы 2 катлы кирпеч бина, ишегалдында кирпеч тамбур.
5. Түбә: түбә конфигурациясе (иелмәле); тимераяк буенча Биеклек билгеләре; конструкцияләр материалы (стропилалар һәм агач бизәкләр); түбә япмасының характеры (фальцев кушылмалы шома металл япма).
6. Фасадларның композициясе һәм архитектур-сәнгати бизәлеше, шул исәптән тәрәзә һәм ишек уемнарының, шул исәптән ялган уемнарның, ризалитларның һәм пьедесталларында геометрик нишалар булган калакларның урнашуын, формасын һәм үлчәмен, цоколь кисемен, рамкада кирпеч кисемнәре һәм кирпеч орнаменты булган киң кат ара поясны, ромб формасындагы һәм түгәрәк филенкаларны, сандрикларны кертеп кәрниз һәм алкалар, консольләргә сохари куелган тәрәзә төбендәге киштәләр, киң түбәле фриз һәм баскычлы консольләр, профильле кәрниз һәм парапет тумбалар, йозак ташлары.
7. Фасад өслегенең бизәлеше: җөйләр чигелгән кызыл кирпечтән салынган йөз өслеге, ак таш цоколь. Колористик чишелеш: балчык кирпечнең табигый төсе.
8. Һәйкәлнең конструктив схемасы: ком-известь эремәсендә таштан һәм лекал балчык кирпечтән терәк кирпеч диварлы каркассыз; буй һәм аркылы терәк диварларның урнашуы һәм әзерләү материалының тибы (кирпечтән салу); перемычкаларның тибы: клинчатыйлар.

* Сак предметы комплекслы фәнни тикшеренүләр һәм реставрация эшләре үткәрү барышында үзгәртелергә мөмкин.

Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан “I гильдия сәүдәгәре, нәселле мактаулы гражданин И. Г. Стахеевның торак йорты", XIX гасыр ахыры төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
сак предметы таблицасы

| № п/п | Сак предметы | Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар |
|---|---|---|
| 1. | Урыны: Ленин урамының тарихи Кызыл линиясендә. |  - каралучы объект<br>1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Әйләнә-тирәдәге табигый һәм мәдәни ландшафт структурасында композицион әһәмияте (роле). | <br>2 нче рәсем. Күләм-киңлек композициясе |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Һәйкәлнең габаритлары, силуэты: тарихи кирпеч диварлар чикләрендә. | <br>3 нче рәсем. Ленин урамы ягыннан гомуми күренеш (төп фасад) |
| 4. | Һәйкәлнең күләм-киңлек композициясе: планында турыпочмаклы 2 катлы кирпеч бина, ишегалдында кирпеч тамбур. | <br>4 нче рәсем. Күләм-киңлек композициясе |
| 5. | Түбә: түбә конфигурациясе (иелмәле); тимераяк буенча Биеклек билгеләре; конструкцияләр материалы (стропилалар һәм агач бизәкләр); түбә япмасының характеры (фальцев кушылмалы шома металл япма). | <br>5 нче рәсем. Ишегалды фасады |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Фасадларның композициясе һәм архитектур-сәнгати бизәлеше, шул исәптән тәрәзә һәм ишек уемнарының, шул исәптән ялган уемнарның, ризалитларның һәм пьедесталларында геометрик нишалар булган калакларның урнашуын, формасын һәм үлчәмен, цоколь кисемен, рамкада кирпеч кисемнәре һәм кирпеч орнаменты булган киң кат ара поясны, ромб формасындагы һәм түгәрәк филенкаларны, сандрикларны кертеп кәрниз һәм алкалар, консольләргә сохари куелган тәрәзә төбендәге киштәләр, киң түбәле фриз һәм баскычлы консольләр, профильле кәрниз һәм парапет тумбалар, йозак ташлары. | <br>6 нчы рәсем. Ян фасад, сохари белән кирпеч ватыклары белән рамланган кат ара пояс, консольле фриз һәм беркетелгән кәрниз. Тәрәзәләрнең масштабы<br><br>7 нче рәсем. Беренче катның тәрәзә уемы конфигурациясе, рустика (разбежка) |
| 7. | Фасад өслегенең бизәлеше: җөйләр чигелгән кызыл кирпечтән салынган йөз өслеге, ак таш цоколь. Колористик чишелеш: балчык кирпечнең табигый төсе. | <br>8 нче рәсем. Ишегалды фасады |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Һәйкәлнең конструктив схемасы: ком-известь эремәсендә таштан һәм лекал балчык кирпечтән терәк кирпеч диварлы каркассыз; буй һәм аркылы терәк диварларның урнашуы һәм әзерләү материалының тибы (кирпечтән салу); перемычкаларның тибы: клинчатыйлар. | <br>9 нчы рәсем. Клинчатый перемычкалы һәм йозаклы ташлы тәрәзә уемы. Сохарилар белән катара кәрниз, Ак таш цоколь |